

Балтач бистәсенең “Искра” урамында бик матур, тырыш гаилә яши. Ул – Мухаметгалиевлар гаилэсе. Гаилә башлыгы Наиль Казан медицина университетын бетереп,бүгенге көндә үзәк шифахәнәдә хирург булып эшли. Тормыш иптәше Рәмзия Казан педагогик университетын тәмамлап, 4 нче балалар бакчасында инглиз телен укыта. Бу тату гаиләнең 3 баласы бар: Әдил – 1 нче сыйныф укучысы, Сәит белән Сәгыйт – 2 нче балалар бакчасына йөриләр.

Мухаметгалиевлар гаиләсе буш вакытларын бер дә заяга үткәрмиләр: җәй, көз көннәрендә җиләккә, гөмбәгә йөриләр.

Спорт төрләре белән кызыксыналар. Балаларда да кечкенәдән спортка карата уңай мөнәсәбәт, сәламәт яшәү рәвеше тәрбиялиләр. Әтиләре белән уллары Әдил һәм Сәит еш кына “Балтач” спорткомплексына шөгыльләнергә йөриләр. Әдил бокс буенча ярышларда призлы урыннар яулап тора. Районыбызда күпләргә бу гаилә үрнәк булырлык.